КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 декабрь г.Казань № 1046

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1093 нче; 2016 ел, 15 февраль, 91 нче; 2016 ел, 2 июль, 454 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 654 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1065 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка «(муниципаль) учреждениеләр),» сүзләреннән соң «шәхси эшмәкәрләр,» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү турында килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне тормышка ашыру белән бәйле чыгымнар төрләре, субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткечләре мәгънәләре, субсидиядән файдалану һәм субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирү формалары һәм вакытлары, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп аларны куллану ихтыяҗы барлыгы турында карар кабул иткәндә финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге һәм мондый карар булмаган очракта субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен (субсидия калдыкларын) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе һәм вакытлары, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруына субсидия алучының ризалыгы (субсидия алучы дәүләт (муниципаль) унитар предприятие, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый берләшмәләр катнашында хуҗалык иптәшлеге һәм җәмгыяте, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре катнашында коммерциячел оешмалар булган очраклардан тыш), Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акчага чит ил валютасы сатып алуны тыю турында нигезләмә, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук Татарстан Республикасының туристлык күргәзмәләрендә, презентацияләрдә, форумнарда һәм «түгәрәк өстәл» утырышларында катнашуын оештыру буенча оештыру кертемнәрен һәм административ эшләрне сатып алганда (түләгәндә), бүлмәләр, җиһазлар һәм кораллары арендасы, дегустацияләр һәм промоакцияләр үткәрү, полиграфия презентация һәм сувенир продукциясе әзерләү һәм таратуны кертеп, операцияләрдән тыш, реклама буенча хезмәт күрсәтүләр, чит телләргә язмача һәм телдән тәрҗемәләрне, материаллар әзерләүне, дизайн эшләүне кертеп, чит дәүләтләрнең туристлык оешмалары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен Татарстан Республикасы территориясендә кабул итү буенча хезмәт күрсәтүләр, россия визасын, медицина иминиятен рәсмиләштерүне, авиа- һәм тимер юл билетлары сатып алуны, транспорт һәм экскурсия хезмәте күрсәтүне кертеп, Татарстан Республикасы вәкилләре чит илдә булу белән бәйле яшәү һәм ашау хезмәтләре күрсәтүләр, мәдәни программаны оештыру, чыгымнар, виза, медицина иминиятен рәсмиләштерүне, авиа- һәм тимер юл билетлары сатып алуны, транспорт һәм экскурсия хезмәте күрсәтүне кертеп, әлеге Тәртиптә билгеләнгән күрсәтелгән акчаны бирү максатларына ирешү белән бәйле яшәү һәм туклану, мәдәни программаны оештыру буенча хезмәт күрсәтүләр (чыгымнарны финанслар белән

тәэмин итүгә субсидияләр бирелгән очракта), субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү күздә тотыла.»;

9 пунктта:

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик зат үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында түгел, ә шәхси эшмәкәр шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;»;

10 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«туристлык оешмасын юридик зат сыйфатында (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсе) яки шәхси эшмәкәрне (Шәхси эшмәкәрләрнең затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсе) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;»;

12 һәм 13 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеген бәяләү Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткечләреннән чыгып гамәлгә ашырыла.

Субсидия алучылар Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына субсидия бирү турында килешү белән билгеләнә торган вакытларда һәм формалар буенча субсидиядән файдалану һәм субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

Субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткече (Е) түбәндәге формула буена билгеләнә:

$$\text{Е} = \frac{\text{К}_{\text{факт}}}{\text{К}_{\text{пл}}} \times 100\ \%,$$

монда:

$\text{К}_{\text{факт}}$ – субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән хисап датасына субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткеченең гамәлдәге мәгънәсе;

$\text{К}_{\text{пл}}$ – субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән хисап датасына субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткеченең пландагы мәгънәсе.

13. Түбәндәге очракларда, субсидияләр Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр вакытында билгеле булган субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырган, субсидия алучы тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракларда тулы күләмдә;

субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән вакытларда субсидиядән файдалану турында һәм субсидиядән файдалануның нәтиҗәлеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшырмаган очракта тулы күләмдә;

субсидия акчасын максатка ярашсыз файдалану очрагында максатка ярашсыз файдаланган субсидия күләмендә;

нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәгән очракта һәр ирешелмәгән нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәсе өчен 10 процент күләмендә.

Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше чираттагы финанс елында Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп әлеге акчага ихтыяҗ барлыгы турында карар кабул иткән очракта әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга файдаланыла ала.

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләргә (субсидиянең калган өлешенә) ихтыяҗ булу турында карары булмаганда әлеге акча хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге пунктта күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары субсидия алучы тарафыннан бозылган очракта Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты субсидияне кире кайтару вакыты узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртипләрен саклауны тикшерүне законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

Субсидия алучылар Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тапшыра торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыларның тиешле вазыйфаи затлары һәм җитәкчеләренә йөкләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин